КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 3 сентябрь г.Казань № 785

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмаларын норматив буенча финанслау турында» 2017 ел, 8 август, 566 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмаларын норматив буенча финанслау турында» 2017 ел, 8 август, 566 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 27 июль, 605 нче, 2018 ел, 13 ноябрь, 996 нчы; 2018 ел, 3 декабрь, 1077 нче; 2019 ел, 28 декабрь, 1232 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмаларында һәркем алырлык һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алуга хокукларны тормышка ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итүгә норматив чыгымнарны исәпләп чыгару тәртибе турындагы нигезләмәнең 3.7 нче пунктындагы бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$C_{upco}$ – чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджетын формалаштырганда кулланыла торган индекслар-дефляторларны исәпкә алып, план елына кадәрге елның 1 сентябре хәленә карата азык-төлек булмаган товарларның уртача базар кыйммәте нигезендә кабул ителә торган уку-укыту әсбаплары һәм укыту чаралары бәясе.»;

әлеге карар белән расланган Гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда тәрбияләнүчеләрне тәрбияләп тотуга норматив чыгымнарны исәпләп чыгару буенча җирле үзидарә органнары өчен методик тәкъдимнамәләрдә:

7 нче таблицага бирелгән астөшермәгә «гомуми белем бирү оешмалары» сүзләре алдына «интернаты булган» сүзләрен өстәргә;

2.11 нче пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

$$«R_v pit = FOT_{v_{pit}} + D_{ug} \times \sum_{i_8 = 1}^{n = 8} N_{i_{8_{pit}}} \times C_{i_{8_{pit}}},»;$$

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$D_{ug}$ – уку планнарына карап, 1 елга уку көннәре саны;»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмаларын финанслар белән тәэмин итү күләмен исәпләп чыгару тәртибендә:

2 бүлектә:

2.2 нче пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

$$«FOSC^t = FOSC^t_{fgos} + FOSC^t_{si} + FOSC^t_{svd} + FOSC^t_{sii} + FOSC^t_{svi} + FOSC_{ogp},»;$$

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«$FOSC_{ogp}$ – гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белем бирүнең мәгариф программалары буенча белем алучыларның түләүсез кайнар ризык белән туклануын оештыруга һәм аның белән тәэмин итүгә финанслар белән тәэмин итү күләме»;

түбәндәге эчтәлекле 2.7 нче пункт өстәргә:

«2.7. Гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белем бирүнең мәгариф программалары буенча белем алучыларның түләүсез кайнар ризык белән туклануын оештыруга һәм аның белән тәэмин итүгә финанслар белән тәэмин итү күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$FOSC_{ogp} = N_{ogp} \times j_{ogp} \times D_{ug},$$

монда:

$FOSC_{ogp}$ – гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белем бирүнең мәгариф программалары буенча белем алучыларның түләүсез кайнар ризык белән туклануын оештыруга һәм аның белән тәэмин итүгә финанслар белән тәэмин итү күләме

$N_{ogp}$ – ел саен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән раслана торган гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белем бирүнең мәгариф программалары буенча белем алучыларның түләүсез кайнар ризык белән туклануын оештыруга һәм аның белән тәэмин итүгә норматив чыгымнар;

$j_{ogp}$ – гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белем бирүнең мәгариф программалары буенча белем алучылар саны;

$D_{ug}$ – уку планы нигезендә 1 елга уку көннәре саны.».

2. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

бу карарның гамәле 2020 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла;

бу карарның 1 нче пунктындагы икенче һәм өченче абзацларының нигезләмәләре, 2021 елдан башлап, Татарстан Республикасының мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында һәркем алырлык һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем белем алуга хокукларны тормышка ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итүгә норматив чыгымнарны формалаштырганда кулланыла.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин